**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе һәм вазыйфалар атамасы үзгәрүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе турында» 2014 елның 25 февралендәге ПУ-217 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 22 ноябрендәге ПУ-1065 номерлы, 2015 елның 30 июлендәге ПУ-688 номерлы, 2017 елның 20 мартындагы ПУ-231 номерлы һәм 2017 елның 3 июнендәге ПУ-459 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан В.А. Герасимовны, Л.Ю. Глухованы, М.А. Җәббаровны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Заһидуллин Рөстәм Илдус улын – Татарстан Республикасы юстиция министрын;

Жуйков Владимир Васильевичны – Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы рәисе урынбасарын (килешү буенча);

Земсков Олег Владимировичны – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасарын;

в) Комиссия әгъзасы Р.С. Сафиуллинның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2017 ел,14 октябрь
№ ПУ-911